ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова, 422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы, 422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

№3
КАРАР

гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Бакча Сарай поселогында 2025 елның 22 ноябрендә гражданнар җыены карарын үзгәртү мәсьәләсе буенча

«Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2026 елда Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Бакча-Сарай поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:-торак пункт территориясен төзекләндерү, дигән сорау буенча 2025 елның 22 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 167 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 110 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 110 катнашучысы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде, тыелып калды – 0 катнашучы.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Бакча Сарай поселогында гражданнар җыены узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

«2026 елда Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Бакча-Сарай поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган

акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:- торак пункт территориясен төзекләндерү, дигән сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга.
3. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Бакча-Сарай поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләрен Вахитов авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Ф.Р. Каримов